РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СТАРОГРИШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ул.Молодежная, д.1, с.Старое Гришкино,
Менделеевский район, Республика
Татарстан, 423642

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ ГРИШКИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур, 1 йорт,
Иске Гришкин авылы, Менделеев
районы,
Татарстан Республикасы,423642

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

8 ноябрь 2024 ел № 12

Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлегенең
Иске Гришкино авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 18 ноябре 14.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Җыен уздыру урыны итеп Иске Гришкино авылы, Яшьләр урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Иске Гришкино авыл мәдәният йортын билгеләргә.
3. «2025 елда Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, 18 яшькә кадәр тәрбиядә балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокды хезмәткә чакырылган гражданнардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга:

«1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (поселок эчендәге юлларны ремонтлау (Азин урамына вак таш җәю, су башнясына таба юлга вак таш җәю);

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын,

скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважинаны ремонтлау);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, триммер алу, Беларус МТЗ-82" тракторына техник хезмәт күрсәтү)?»

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 3 көн дәвамында. мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Иске Гришкино авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И.Алексеев